# «Һәр мизгел матур үзенчә».

(1-октябрь Өлкәннәр көненә багышланган сценарий )

Әзерләде Ваныш авыл клубы

мөдире Мусина Г.З.

2015ел.

Хәерле көн, хөрмәтле авылдашлар! Исәнмесез әбиләр,бабайлар,апалар,абыйлар! Бүген бездә олы бәйрәм. 1-октябрь өлкән яшьтәгеләрне хөрмәтләү көне буларак билгеләп үтелә. Бүгенге бәйрәмебезнең кунаклары- хезмәт ветераннары, тормыш юлларын авыл тормышы белән бәйләп, лаеклы ялга чыккан авылдашлар. Әйе, сез чынлап та авылыбызның хөрмәткә лаек кешеләре. Тыныч тормышта яшәвебезгә быел төгәл 70 ел булды. Безнең алда – өлкән буын кешеләре.Дөньяның ачысын да, төчесен дә, сугышын да, афәтен дә үз жилкәләрендә күтәргән,бүгенге яшь буын рәхәт тормышта яшәсен өчен гомерен дә, сәламәтлеген дә кызганмаган олы йөрәкле авылдашларыбыз утыра. Ирләрме ул, хатын-кызлармы, кем генә булсада гомерләре олы бер язмышка тиң аларның. Үткәннәр ерак калды, ләкин үткәнне онытырга безнең хакыбыз юк.

Озын да ул,авыр да ул
Сез үткән юллар.
Онытмаслар мәңге сезне
Килер буыннар.

Хөрмәтле авылдашлар! Сезгә бүгенге көнне тик исәнлек-саулык, түземлелек, озын гомер, гаиләгезгә иминлек һәм бәхет телисе генә кала. Ә хәзер барлык борчуларыгызны, сызлануларыгызны, эшләрегезне онытып ял итеп алыгыз. Бу очрашу сезнең күңелләрдә матур истәлекләр калдырсын иде.
Котлау өчен сүз авыл хакимияте башлыгы Ирек Фидәрис улы Саетгалиев сезгә бирелә. Рәхим итегез!
Котлау өчен сүз мәктәп директоры Мөнирә Барис кызы Камалова сезгә бирелә. Рәхим итегез!
Котлау өчен сүз ветераннар совете рәисе Фәния Гадел кызы Гарейшина сезгә бирелә. Рәхим итегез!
Бәйрәм белән котлап безнең нәни дусларыбыз килгән, әйдәгез аларга сүзне бирәбез.( сүз садик балаларына)

Нигә картлык шатлык түгел диләр
Картлыкны да шатлык итәек.
Балалар, оныклар белән бергә
Шатланышып гомер итәек.
Картлык шатлык була аладыр ул,
Балалар булса игътибарлы.
Карт кешегә әлләни кирәкми.
Якты чырай, тәмле сүз бары.

Нигә картлыкны шатлык итеп соң,
Яшәмәскә безгә дусларым.
Яшик әле, яшик уйламыйча
Күпме гомерләребез барын.
Бүген бездә кунакта иң якын кешеләребез- безнең сөекле картәниләребез,картәтиләребез. Мин сезне, бер яшьлектә, бер картлыкта- диеп “Ягез әле, өлкәннәр” дигән бәйгедә катнашырга чакырам.
Бер утыру- үзе бер гомер дип,
Бабайлар бит юкка әйтмәгән.
Бер очрашып серләр бүлешү-
Бу гадәтләр әле бетмәгән.
Уңыш сезгә, уңыш безгә.
Елмаеп көлеп торсын.
Шушы бәйге сезнең арада
Дуслык нигезен корсын!
**Беренче бәйге.**
“Исәнмесез,бу мин”- дип атала. Командалар үзләре турында таныштыралар.
Хөрмәтле авылдашлар сезнең алдыгызда татар биюе белән Алина Нуртдинова.
**Икенче бәйге.**
1) Буй белән тезелергә.
2) Аяк киеме размеры белән тезелергә.
3) Исемнәр алфавит буенча тезелергә.
4) Яшь буенча тезелергә.

**Өченче бәйге.**
Әкият бәйгесе. Бер команда” Шалкан әкияте”н күрсәтә,икенче команда “Чуар тавык” әкиятен күрсәтә.
Алып баручы. Бабай шалкан утырткан. Шалкан зу-у-ур булып үскән.
Бабай. (Чыга, кулын каш өстенә куеп, шалкан тирәсендә йөри).
Йә, Аллам, йә, Аллам.
Качан үскән бу шалкан?
Кайсы ягыннан тартыйм.
Ничек кенә чыгарыйм?
Тукта, әбине чакырыйм әле. Әбисе, әбисе, дим, чык әле монда.

Әби. (Яулыгын төзәткәләп).
Ятып кына торыйм, дисәм,
Тагын нигә чакыра?
Нәрсә булган бу бабайга,
Шалканга карап тора?

Бабай. (Шалканга күрсәтеп).
Күр, әбисе, нинди шалкан
Үскән безнең бакчада.
Бергәләп тартып чыгарыйк.

Тотын минем аркага.

Алып баручы. Әби бабайга, бабай шалканга тотынган, тарталар – тарталар, тартып чыгара алмыйлар икән.

Әби. (Маңгаендагы тирен сөртеп ала).
Булмый, бабай, туктале.
Кызны чакырыйк әле.
Кызым. Кызым. Алия.
Кил әле син бирегә.

Кыз.
Ай, битләрем алланды.
Иреннәрем кызарды.
Әбием, тагын нәрсәгә.
Мине өйдән чыгардың?

Әби. (Кулы белән күрсәтеп).
Кара, кызым, күрәмсең.
Шалкан ничек үскәнен.
Бергәләп тартып карыйк.
Бу шалканны чыгарыйк.
(Кыз, бии-бии, шалкан тирәли әйләнеп чыга, әбигә килеп тотына).

Алып баручы. Кыз әбигә, әби бабайга, бабай шалканга тотынган. Тарталар – тарталар, тартып чыгара алмыйлар.
Кыз. (Кулларын карый).
Ай, кулым арыды.
Тартуы авыр ла.
Акбайны чакырыйк.
Булышсын тартырга.
Акбай. Акбай. Кайда син.?
Ник бирегә килмисең.
Акбай, булыш, бик авыр.
Бу шалканны тартуы.

Акбай. (Чыга).
Һау- һау-һау. Ни булды монда?
Көн буе саклыйм йортны.
Бер каракны китермим,
Энәгә дә тидермим.
Һау-һау. Нәрсә булды, Алия?

Кыз. (Күрсәтеп).
Тотын минем артыма.

Әйдә шалкан тартырга.
(Акбай кызның артына тотына).

Алып баручы. Акбай кызга, кыз әбигә, әби бабайга, бабай шалканга тотынган. Тарталар – тарталар, тартып чыгара алмыйлар икән.

Акбай. (Туктап, тирен сөртә).
Һау-һау-һау. Булмый болай.
Шалкан бигрәк зур булган.
Кая син, Мияубикә?
Ярдәмгә килеп җит лә.

Мияубикә. (Киерелеп – тартылып чыга).
Мияу-мияу-мияу мин.
Һәрвакытта уяу мин.
Сөт эчәм, тычкан тотам.
Йокларга бик яратам. (Киерелеп ала).
Акбай-Акбай. Ник уяттың мине?

Акбай. (Күрсәтеп).
Бабай шалкан үстергән.
Шалкан гаҗәп зур булган.
Тартып-тартып карыйбыз.
Һич чыгара алмыйбыз.
Булыш әле, Мияубикә.

Алып баручы. Песи эткә, эт кызга, кыз әбигә, әби бабайга, бабай шалканга тотынган. Тарталар – тарталар, тартып чыгара алмыйлар икән.
(Барысы да уфылдап тирләрен сөртәләр).

Мияубикә. Мияу-мияу, арыдым.
Ә шалкан чыкмый һаман.
Бергә-бергә җиңел булыр.
Ярдәм сорыйк тычканнан.
Тычкан-тычкан, чи-чи-чи.
Син кайларда йөрисең?
Һич тимәскә сүз бирәм.
Килсәң иде бирегә.

Тычкан. (Чи-чи-чи килеп чыга).
Качып ипи кимердем.
Әллә шуны сизденме?
Мияубикә, ни кирәк?
Чабып килдем тизрәк.

Мияубикә. (Күрсәтеп).
Бабай үстергән шалкан.
Шалканы бик зур булган.
Тычкан, ярдәмең кирәк,
Тартып чыгарыйк тизрәк.
Алып баручы. Тычкан песигә, песи эткә, эт кызга, кыз әбигә, әби бабайга, бабай шалканга тотынган. Тарталар – тарталар икән – шалкан килеп тә чыккан.

Шалкан. (Торып баса).
Бабай чәчте орлыгым.
Сулар сибеп үстерде.
Витаминлы, бик файдалы.
Тәмле булып өлгердем.
(Балалар түгәрәк ясап, шалканны уртага алалар һәм җырлыйлар).

Барысы бергә.
Әй, бабабыз бик уңган.
Үстергән шундый шалкан.
Шалкан үскән, зур булган.
Бөтен бакчабыз тулган.
Без әбигә булышырбыз.
Бергәләп тәмләп ашарбыз.
(Кунакларга карап, кулларын җәеп).
Шалканнан авыз итәргә.
Без сезне дә чакырабыз.

"Чуар тавык"
Борын-борын заманда, яшәгән ди , булган ди, бабай белән әби. Аларның Чуар тавыклары булган-Кыт-кытак, кыт-кытак!
Беркөнне тавык йомырка салган,ләкин гади түгел,ә алтынны. Бабай йомыркага сукты, сукты, сукты-сукты-вата алмады. Әби теге йомыркага сукты-сукты, сукты-сукты –вата алмады.
Шул тирәдә бер тычкан –йөгереп чыкты. Койрыгы йомыркага тиеп китте дә йомырка тәгәрәп төште.Бух! урталайга ярылды. Бабай елый. Әби елый. Ә Чуар тавык аларна болай дигән, кыт-кытак! Елама бабай,елама әби, мин сезгә тагын йомырка салырмын. Ләкин алтынны түгел, ә гадине!

**Дүртенче бәйге.**
"Булсаң зирәк-әйт тизерәк".
Халкыбыз аш-суга бәйле табышмаклар да уйлап чыгарган. Ә хәзер мин сезгә табышмаклар әйтәм.
1. Эче тулы вак халык
   Түрдә утыра мактанып (бәлеш)

2. Үзе генә ашалмый
Аннан башка аш бармый.

3.Лыбыр-лыбыр сөйләшә
Батырып болгатсаң тына (ботка)
4.Ак тирмәнең ишеге дә
Тишеге дә юк.
5. Шулпасын эчәләр
Итен түгәләр (чәй)
6. Ак кына, тәмле
Суга салсаң юк була (шикәр)

**Бишенче бәйге.**

Төрле бию көенә команда белән биергә. Көй башлануга кайсы команда житезрәк биеп китә.

Кайнар хисләремне жырлар белән
Моңнар белән сезгә тапшырам.
Әнә шул жырлар, шул моңнардан
Әйтелмәгән сүзләр бар сыман.
Иң зур бүләк булсын безнең жырлар
Бәхет тулсын сезнең күңелдә.
Шатлыкларны уртак итик әле
Жырлыйк әле матур көйләргә.

**Жырлый Ирина һәм Илиза Низамовалар.**

**Алтынчы бәйге.**

Мәктәптә ятлаган бер шигырьне сөйләп күрсәтергә.

**Хөрмәтле авылдашлар! Сезнең өчен бии Юлия Муллагалиева.**

**Жиденче бәйге.**

Такмаклар бәйгесе.
Алмашлап командалар такмаклар жырлыйлар.

**Бәйрәм белән сезне котлый Илиза Низамова һәм Реналь Шарипов.**

**Сигезенче бәйге.**

Командалар бер концерт номеры бүләк итә.

Хөрмәтле картәни, картәтиләр!
Моңаймагыз,
Гомерләрнең көзләренә
Аяк бастым-диеп.
Кырау төшә диеп, чәчләргә.
Яшәгез, нур сибеп дөньяга
Үрнәк булып безгә яшьләргә.
Сәламәтлек ташламасын сезне
Һәр көнегез үтсен шатлыкта.
Яшәү яме, дөнья иминлеге

Юлдаш булсын сезгә картлыкта.